РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА
МЕЩЕРЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАРЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 14 » июль 2026 ел № 1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Карлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында» 2026 елның 10 июлендәге 1-15 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Карлы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең «Карлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү турындагы мәсьәләне тикшерүдә гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән катнашу хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Карлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә кушымта итеп бирелә торган карта-схема нигезендә үзгәртү мәсьәләсе буенча (янәшә), гавами тыңлаулар уздыруны 2026 елның " 25 " июленә 14:00 сәгатькә Карлы авыл җирлегенең Карлы авылы мәдәният йорты бинасында ТР, Буа районы, Карлы авылы,Татарстан ур., 66 йорт. адресы буенча билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларда карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2026 елның «24» июленә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә:

ТР, Буа районы, Карлы авылы, Муса Җәлил урамы, 107 йорт, Карлы авыл җирлеге башкарма комитеты,телефон +7(84374) 40-7-94.

3. Әлеге карар Карлы авыл җирлегенең ТР, Буа районы, Карлы авылы,Муса Җәлил урамы һәм 107 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Карлы авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Мифтахов

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Карлы авыл җирлеге башлыгының 14.07.2026 елдан № _
карарына кушымта

**Үзгәрешләрне исәпкә алып, муниципаль**

**берәмлекләр чикләренең**

**Карта-схемасы**

